**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**29 сентябрь, 2023 ел** **№ 327**

# Биектау муниципаль районы Советының «Гомуми белем бирү учреждениеләре арасында иң яхшы мәктәп яны өйрәнү-тәҗрибә участогына район смотр-конкурсын үткәрү нигезләмәсен раслау турында» 2023 елның 28 апрелендәге номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Гомуми белем бирү учреждениеләре арасында иң яхшы мәктәп яны өйрәнү-тәҗрибә участогына район смотр-конкурсын үткәрү нигезләмәсен раслау турында» 2023 елның 28 апрелендәге номерлы карары белән расланган Иң яхшы мәктәп яны өйрәнү-тәҗрибә участогына район смотр-конкурсын уздыру нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Конкурсны оештыручылар һәм анда катнашучылар» 2 нче бүлегенең «Конкурста жюри» бүлекчәсенең 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Смотра-конкурста катнашучылар булып, авыл хуҗалыгы һәм агроэкология өлкәсендә УОУга ия булган укыту-тәҗрибә, тикшеренү һәм гамәли эшләр алып баручы белем бирү оешмалары (төп гомуми белем бирү һәм урта гомуми белем бирү мәктәпләре) торырга мөмкин.»

1.2. 3 нче бүлекнең 3.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Смотр-конкурс түбәндәге чараларны үз эченә ала:

- гомуми белем бирү оешмалары УОУ базасында балалар һәм яшьләр белән белем бирү һәм гамәли авыл хуҗалыгы эшчәнлеген оештыру;

- төп һәм урта гомуми белем бирү оешмалары арасында иң яхшы гомуми белем бирү оешмаларының эш тәҗрибәсен сайлап алу»;

1.3. Иң яхшы мәктәп яны өйрәнү-тәҗрибә участогына район смотр-конкурсын үткәрү буенча нигезләмәгә 1 нче кушымтадагы Белем бирү оешмаларының өйрәнү-тәҗрибә участоклары район смотр-конкурсында катнашучының анкета-заявкасының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Номинация: «Урта һәм төп гомуми белем бирү учреждениеләре арасында иң яхшы мәктәп яны участогы»

2. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең

рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов